**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

ПГ-63 18.03.2025

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 12 февралендәге ПР-22 номерлы «Актаныш муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Кадрлар үзгәрү сәбәпле, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Актаныш муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 12 февралендәге ПР-22 номерлы карарының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә һәм административ комиссия составын яңа редакциядә расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

2.1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Актаныш муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 12 февралендәге ПР-22 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 05 августындагы ПР-141 номерлы карары.

3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Ш.Бариев

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
“____”_______2025, №____
1 нче кушымта

Актаныш муниципаль районының административ комиссиясе составы

| |
|---|
| **Бариев И.Ш. -** административ комиссия рәисе, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе; |
| **Габдулхаев И.И. -** административ комиссия рәисе урынбасары, Актаныш муниципаль районы Башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| **Әхтәмова А.А**. - административ комиссиянең җаваплы секретаре. |
| **Комиссия әгъзалары:** |
| **Дәүләтов И.И.** - полициянең участок уполномоченныйлары бүлеге һәм балигъ булмаганнар эшләре бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| **Усманов Р.М.** - ММЧ белән эшләү бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| **Шәрәфиева Э.Д. -** Советның авыл җирлекләре белән эшләү буенча оештыру бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| **Әнвәрова Р.Я. -** Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының бюджет бүлеге баш белгече (килешү буенча). |